**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

30.12.2020 № 398

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2014 елның 13 декабрендәге 707 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 30 июлендәге 439 номерлы, 2016 елның 5 апрелендәге 221 номерлы, 2017 елның 9 гыйнварындагы 2 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге 342 номерлы, 2017 елның 16 декабрендәге 731 номерлы, 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы һәм 2020 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Эш төркеме составыннан С.Н. Гариповаңы, М.Ш. Долговны, О.В. Назаровны, И.С. Нуриәхмәтовны чыгарырга;

Эш төркеме составына кертергә:

Громушкин Петр Николаевичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгының беренче урынбасарын (килешү буенча);

Козачек Ирина Владимировнаны – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Наумова Юлия Ивановнаны – Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасарын (килешү буенча);

Руденко Юрий Алексеевичны – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча бишенче бүлеге җитәкчесен (килешү буенча).

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**